| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br><br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br><br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.04.2020 № 623-п

2017-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программага үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “2017-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программаны раслау турында”гы 2016 елның 28 октябрендәге 1328-п номерлы карары белән расланган, 2017-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программага (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспорты таблицасында “Программаны финанслау күләмнәренең еллар һәм чыганаклар буенча бүленеше” юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау күләмнәре | 2017 – 2022 елларда Программаны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы бюджеты хисабына финанслауның гомуми күләме 90 932,171 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2017 елда – 15 978,625 мең сум;<br>2018 елда – 15 136,410 мең сум;<br>2019 елда – 14 259,963 мең сум;<br>2020 елда – 15 457,173 мең сум;<br>2021 елда – 14 700,000 мең сум;<br>2022 елда– 15 400,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (Чираттагы финанс елына һәм план чорына) Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә ачыкланачак.<br>Экономияләнгән акчаларның калган өлешен ел саен юл хәрәкәте куркынычсызлыгы буенча чаралар үткәрү өчен җибәрергә. |

”.

1.2. 3 таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“

## 2017-2022 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын ремонтлау һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программаның төп чаралары

3 Таблица

| № п\п | Чараның исеме | Башкаручылар (килешү буенча) | Финанслау күләме һәм чыганаклары (мең сум) | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Смета документларын эшләү | ТР Саба муниципаль районы җирлекләре башлыклары | Саба муниципаль районы бюджеты, Барлыгы 90 932,171, шул исәптән: 2017 ел-15 978,625; 2018 ел-15 136,410; 2019 ел-14 259,963; 2020 г – 15 457,173; 2021 г-14 700,000; 2022 г-15 400,000, әлеге программаның 4 таблицасында күрсәтелгән финанс чараларын бүлү нигезендә | агымдагы елның апрель - март айлары |
| 2 | Смета документларын тикшерү | “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчы хезмәте” МУП, ТР Финанс министрлыгының Казначылык департаментының Саба районы территориаль бүлеге | | тикшерүгә тапшырылган көннән соң 1 атна эчендә |
| 3 | Ремонт эшләре үткәрү | Ачык аукцион нәтиҗәләре буенча электрон сатуларда (торги) җиңгән подрядчы оешма | | контрактта күрсәтелгән вакыт |
| 4 | Техник күзәтчелек һәм башкарыла торган эшләрнең сыйфатын контрольдә тоту | “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчы хезмәте” МУП | | эшләрне башкару барышында |
| 5 | Башкарылган эшләрне кабул итү һәм объектны файдалануга тапшыру | Заказ бирүче – (объектны баланста тотучы), Заказ бирүче-төзүче – “ТР Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчы хезмәте “ МУП | | ремонт эшләре тәмамланганнан соң |

”;

1.3. 4 таблицаны әлеге карарның 1 кушымтасы нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы И.Б.Таиповка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башкарма комитетының
______________________
______________________
номерлы карарына
1 кушымта

**2017-2022 елларда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлауга юл фондының финанс чаралары бүленеше**

4 Таблица

| № | АВЫЛ ҖИРЛЕКЛӘРЕ ИСЕМЕ | Еллар буенча бүленеш (мең сум) | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 | 2018 | 2019 | 2020 | 2021 | 2022 |
| 1. | Саба ШҖ | 12769,409 | 14139,060 | 6455,783 | 11260,673 | | 5569,256 |
| 2. | Арташ АҖ | | | | | | 1956,364 |
| 3. | Олы Кибәче АҖ | 1073,112 | | | | 2786,858 | |
| 4. | Олы Нырты АҖ | | | | | | 2469,574 |
| 5. | Олы Шыңар АҖ | | | | 1059,270 | | |
| 6. | Курсабаш АҖ | 894,489 | | | | 3519,361 | |
| 7. | Югары Симет АҖ | | | | | | 2257,848 |
| 8. | Явлаштау АҖ | | | | | | |
| 9. | Эзмә АҖ | | | 1290,956 | | 2956,480 | |
| 10. | Иштуган АҖ | | | | | | |
| 11. | Килдебәк АҖ | | | | | | |
| 12. | Түбән Шытсу АҖ | | | | | | |
| 13. | Мишә АҖ | | | | 1845,020 | | |
| 14. | Мичән АҖ | | | | | | |
| 15. | Сатыш АҖ | 1241,615 | 997,350 | | | | 1245,857 |
| 16. | Иске Икшермә АҖ | | | | | | |
| 17. | Тимершык АҖ | | | | 1292,210 | | |
| 18. | Шекше АҖ | | | | | 2785,442 | |
| 19. | Юлбат АҖ | | | | | 2651,868 | |
| 20. | Шәмәрдән АҖ | | | 6513,224 | | | 1901,101 |
| | **БАРЛЫГЫ:** | **15978,625** | **15136,410** | **14259,963** | **15457,173** | **14700,000** | **15400,000** |